БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 01 » сентябрь 2021 ел № 272

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турында

«Гражданнар оборонасы турында» 1998 елның 12 февралендәге 28-ФЗ номерлы Федераль закон,«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 21 пункты, «Россия Федерациясендә гражданнар оборонасы турында нигезләмәне раслау хакында» 2007 елның 26 ноябрендәге 804 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары,«Татарстан Республикасында гражданнар оборонасы турында» 2020 елның 20 февралендәге 10-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турында нигезләмәне раслау хакында» 2008 елның 22 ноябрендәге ПУ-598 номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указы, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 27 гыйнварындагы ПУ-27 номерлы Указы, «Муниципаль берәмлекләрдә һәм оешмаларда гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турында нигезләмәне раслау хакында» 2008 елның 14 ноябрендәге 687 номерлы Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы боерыгы, «Татарстан Республикасында гражданнар оборонасы чараларын тәэмин итү һәм коткару хезмәтләрен (гражданнар оборонасы хезмәтләрен) булдыру турында» 2010 елның 15 гыйнварындагы 6 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 2020 елның 4 апрелендәге 20 номерлы Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы башлыгы карарры нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының гражданнар оборонасы штабы дип аталган гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча гражданнар оборонасы өлкәсендәге бурычларны хәл итүгә вәкаләтле орган төзергә.

2. Расларга:

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында гражданнар оборонасын оештыру схемасын (1 нче кушымта);

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының гражданнар оборонасы штабы турында нигезләмәне (2 нче кушымта);

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының гражданнар оборонасы штабы структурасы (3 нче кушымта);

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының гражданнар оборонасы штабы начальнмгының функциональ бурычларын (4 нче кушымта).

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» интернет – ресурсында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе А.Ф. Хәйретдинов